МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

24.01.2025 Казан ш № 30

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 16 июлендәге 473 номерлы боерыгы белән расланган Ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалануына юллама алу өчен Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен исәпкә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү хакында

Дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалануына юллама алу өчен Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен исәпкә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 16 июлендәге 473 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 10.08.2016 №465, 14.05.2018 №363, 10.10.2018 №935, 22.01.2019 №45, 03.04.2019 №226, 05.08.2019 №595, 23.10.2019 №888, 14.07.2020 №514, 28.09.2020 №680, 08.09.2021 №645, 14.02.2022 №102, 29.08.2022 №811, 08.12.2022 №1085, 09.03.2023 №143, 20.07.2023 №587, 05.08.2024 №548, 12.11.2024 №755 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалануына юллама алу өчен Татарстан Республикасы

пенсионерларының аерым категорияләрен исәпкә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2.6.1 пунктның тугызынчы абзацында «өстәмә рәвештә» сүзе алдыннан «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 20.10.2022 ел, №1122 карарының 1 пунктындагы өченче абзацы белән билгеләнгән» сүзләрен өстәргә.

Министр Э.Ә. Зарипова